**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2015 елның «08» сентябреннән № 250

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан торак урыннарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның гаризаларын найм бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибе турында»**

Россия Федерациясе Торак Кодексының 91.14 статьясындагы 5 өлешенең 1 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3, 4 өлешләре, «социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы, 1 өлешнең 6 пункты, 1 өлешнең 6 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын найм бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында novosheshminsk.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2015 елның «08» сентябреннән
250 номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан торак урыннарны найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын найм бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу социаль куллану тәртибе**

1. Әлеге норматив акт белән, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алу Тәртибе түбәндә күрсәтелгән найм бирүчеләр өчен билгеләнә:

а) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты;

б) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтле;

в) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан төзелгән, хосусый торак фондының торак урыннары милекчеләре булган яисә мондый торак урыннарның милекчеләре булган һәм «социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем буенча мөнәсәбәтләрне җайга салу турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 5 декабрендәге 1318 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган оешмалар.

2. Найм бирүче социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү (алга таба - гариза) турында, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнар исәбенә алынган гражданнар (алга таба - мөрәҗәгать итүче) тарафыннан гаризаларны исәпкә ала.

3. Гариза әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча бирелә.

4. Гариза шәхсән бирелгәндә аны исәпкә алу гариза бирүче каршында турыдан-туры башкарыла. Гаризаны почта аша җибәргән очракта, гаризаны исәпкә алу найм бирүче тарафыннан почта аша гариза җибәрелгән көнне башкарыла.

5. Гариза социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гариза биргән гражданнар реестрында (әлеге тәртиптәге 2 нче кушымта) әлеге тәртип нигезләмәләрен исәпкә алып, керүче документларны теркәү өчен билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

6. Мөрәҗәгать итүчегә гариза биргән көнне гариза алу һәм исәпкә алу турында расписка бирелә, ул әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында китерелгән. Гариза почта аша җибәрелгән очракта, гариза алу һәм исәпкә алу турында расписка найм бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән адрес

буенча, найм бирүче тарафыннан почта аша гариза җибәрелгән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

7. Найм бирүче гаризаны исәпкә алган көннән соң бер ай эчендә тикшерү үткәрергә хокуклы:

а) гаризада күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслегенә;

б) мөрәҗәгать итүчене социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗларны исәпкә алуны;

в) социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын найм алучының, шул исәптән муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган социаль файдаланудагы наемга бирелүче йортларда (башка найм бирүчеләр булмаганда) шундый ук гариза бирмәвен.

8. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча найм бирүче тикшерү тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр җибәрә. Хәбәр мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән адрес буенча, җибәрелгән документларны тасвирлап, почта тапшыру турында хәбәрнамә белән аша җибәрелә һәм шәхсән имза куйдырып тапшырыла.

9. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә, найм бирүче гаризада булган мәгълүматларның дөрес булмавын ачыкласа, найм бирүче мөрәҗәгать итүчегә әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәдә бер ай эчендә дөрес белешмәләр белән яңа гариза тапшырырга тәкъдим итә. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан бер ай вакыт эчендә яңа гариза тапшырмаган очракта йә тикшерү Россия Федерациясе Торак Кодексының 91.14 статьясындагы 4 өлешендә каралган гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, гаризаны исәпкә алу турындагы реестрдагы язма найм бирүченең язма карары нигезендә юкка чыгарыла.

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алу Тәртибенә
1 нче кушымта

**Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гариза формасы**

________________________________
(найм бирүченең исеме)
кемнән________________________________
(Ф.И.О., яшәү урыны, телефоны)

**Гариза**

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын найм килешүе буенча торак бина бирүегезне сорыйм.

Мин социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын найм шартнамәсе буенча торак урыны бирү турында ________________________________ (карар кабул иткән орган исеме) карары нигезендә 20 елның «___ » __________ __________________________ мохтаҗлар исәбенә алындым.

Торак бинада гаиләм белән/ ялгыз яшәүне күздә тотам (ассызыкларга кирәк).
Гаилә составы:

| №№ | Фамилия, исем, атасының исеме | Туганлык дәрәҗәсе | Туган көне, ае, елы |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Мин найм бирүченең шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, шул исәптән әлеге гаризаны исәпкә алу өчен кирәк булган барлык гамәлләрне башкару максатыннан, җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны зарарсызлау, блоклау, юк итүгә ризалык бирәм.

________________________________________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.)

________________________ «_____» ______________ 20 __ ел
(имза) (дата)

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алу Тәртибенә
2 нче кушымта

## Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гариза биргән гражданнарның реестры формасы

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гариза биргән гражданнарның
реестры

____________________________________________________________

(найм бирүченең исеме)

| №№ т\б | Гариза кергән дата | Мөрәҗәгать итүче һәм аның гаиләсе турында мәгълүмат | | | | Гражданнарны торак урыннары бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую вакыты һәм мондый карар реквизитлары | Мөрәҗәгать итүченең расписка алуына имзасы һәм аны алу датасы | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын найм шартнамәсен төзү яки гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту һәм баш тарту нигезләре турында белешмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Мөрәҗәгать итүче һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының ФИА, шәхесне раслаучы документлары турында белешмәләр | Даими яшәү урыны | Туган көне, ае, елы | Мөрәҗәгать итүчегә карата туганлык дәрәҗәләре | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

**Искәрмә:**

1.Таблицаның 1 колонкасында мөрәҗәгать итүчегә реестр буенча бирелгән тәртип номеры күрсәтелә, мәсәлән: «1». Мөрәҗәгать итүченең гаризасында аның гаиләсе берничә кешедән торуы күрсәтелсә, бу гаризаны теркәүгә карата барлык кирәкле язмалар бер тәртип номеры астында башкарыла. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче турында һәм аның белән бергә яшәүче аның гаилә әгъзалары турында мәгълүматларны тутыруга тиешле күләмдә юллар бирелә.

2.Таблицаның 2 колонкасында гариза керү датасы күрсәтелә.

3.Әгәр мөрәҗәгать итүченең гаризасында аның гаиләсенең берничә кешедән торуы күрсәтелсә, мөрәҗәгать итүче һәм аның гаиләсенең һәр әгъзасына карата барлык кирәкле язмалар таблицаның 3-6 колонкаларында бер тигезлектә урнаштырыла.

4. Таблицаның 7 нче колонкасында вәкаләтле органның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую турындагы карарының реквизитлары (датасы һәм номеры) күрсәтелә.

5. Таблицаның 7 нче колонкасында гражданнарны торак урыннары бирүгә мохтаҗларны исәпкә кую вакыты вәкаләтле орган карары нигезендә һәм бу карарның реквизитлары күрсәтелә.

6. Таблицаның 8 колонкасында граждан найм бирүченең социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү турында гариза алу турындагы расписканы алуны раслаучы аны алу датасын күрсәтеп имза куя. Мәсәлән: *«Расписканы 2015 елның 12 июлендә алдым (гариза бирүченең имзасы)»*. Гариза, найм бирүче тарафыннан гаризаны алу һәм исәпкә алу турындагы расписка почта аша җибәрелгән очракта, таблицаның 8 нче колонкасына языла: *«Расписка почта*

*тарафыннан 2015 елның 12 июлендә җибәрелгән. _______ _ _ __(Ф. и. о.) ______________ ( имза)».*

7. Таблицаның 1-8 нче колонкалары найм бирүчеләр тарафыннан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алганда.

8. Таблицаның 9 нчы колонкасы найм бирүчеләр тарафыннан социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алуны туктатканда тутырыла.

9. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урынын найм шартнамәсен төзү турындагы белешмәләрне тутырганда таблицаның 9 колонкасында шартнамәне төзү датасы, бирелгән торак урыны мәйданы, срогы күрсәтелә. Мәсәлән, *«2016 елның 17 апрелендә социаль файдаланудагы торак фондының 74,7 кв.м мәйданлы Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Чапаев ур., 3, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан торак урынына ун елга найм шартнамәсе төзелде».*

10. Гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту һәм баш тарту сәбәпләре турында белешмәләрне тутырганда 9 таблицаның колонкасында, мәсәлән, «2016 елның 27 апрелендә баш тартылган» дип күрсәтелә, мөрәҗәгать итүченең социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алудан Россия Федерациясе Торак кодексының 91.13 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органының норматив хокукый акты белән билгеләнгән мондый исәпкә алу тәртибе нигезендә баш тарту сәбәпләре күрсәтелә.

11. 9 таблицаның колонкасында гариза исәпкә алу турындагы язма юкка чыгрылганда, *«Язма найм бирүченең 20____ елның «_____» ________ ____номерлы карары нигезендә юкка чыгарылган»* дип языла.

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан торак урыннары бирү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алу Тәртибенә
3 нче кушымта

**Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү турында гариза алу хакында расписка формасы**

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү турында гариза алу хакында
расписка

Әлеге документ беләнраслана:

гариза бирүче

___________________________________________________________________

(Ф. И. О.)

биргән, найм бирүче

___________________________________________________________________

(найм бирүченең исеме)

социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыны бирү турында гариза 20 елдан алган һәм аңа социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында гариза биргән гражданнар реестрында тәртип номеры бирелгән.

Гаризаны алгпн_____________________________________________________
(вазыйфасы)

___________________________________________________________________
(гаризаны алучының Ф.И.А.)

_________________________ « _____ » _______________ 20____ ел
(имза) (дата)

М.П.